РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**14 апрель 2023 ел** **Чистай шәһәре** **№ 22/2**

Татарстан Республикасы
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 85 - 87 статьялары нигезендә, Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2014 елның 29 гыйнварындагы 32/1 номерлы карары белән кабул ителгән «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (Чистай муниципаль районы Советының 2015 елның 28 апрелендәге 45/1 номерлы, 2015 елның 18 декабрендәге 3/4 номерлы, 2017 елның 10 февралендәге 17/2 номерлы, 2017 елның 7 августындагы 23/1 номерлы, 2018 елның 29 мартындагы 32/1 номерлы, 2018 елның 23 ноябрендәге 39/1 номерлы, 2019 елның 25 июлендәге 45/1номерлы, 2020 елның 13 маендагы 55/1 номерлы, 2021 елның 21 апрелендәге 7/1 номерлы, 2022 елның 27 маендагы 15/4 номерлы карарлары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 16 статьяда:

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлаулар уздыру турындагы мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, шул исәптән районның рәсми сайтында урнаштырылырга, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт (функцияләр) күрсәтүләрнең бердәм порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гавами тыңлаулар һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән район халкы район башлыгына халык

тыңлауларына чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты яки мәсьәләсе буенча, шул исәптән “Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрергә хокуклы.

Район башлыгы килгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерүне оештыра.».

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре районның рәсми сайтында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында ачык тыңлаулар уздырылганнан соң, 5 эш көненнән дә соңга калмыйча бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.»;

1.2. 25 статьяга түбәндәге эчтәлекле 12.1 пункт өстәргә:

«12.1. Депутат җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән район Советының оештырылган бар утырышларында булмаган очракта, район Советы карары белән район Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

1.2. 28 статьяның 1 пунктында:

9 пунктчада «Районның Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе» сүзләрен «кандидатның квалификация таләпләренә туры килүе турында Татарстан Республикасы финанс органы бәяләмәсе нигезендә районның Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга.»;

1.3. 13 пунктчаны үз көчен югалткан дип таныргa;

1.4. 35 статьяның 1 пунктында һәм 38 статьяның 3.1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 44 статьяның 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 47 статьяның 2 пунктындагы 2 пунктчасында һәм 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

1.7. VIII бүлек үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне дәүләт теркәвеннән соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы Башлыгы **Д.А. Иванов**